Татарстан Республикасы  Лаеш муниципаль районы
МБГБУ"Россия Федерациясе Герое Ахметшин Марат Радикович
исемендәге Атабай урта гомуми  белем  мәктәбе"

| | | |
|---|---|---|
| Каралды | Килешенде | Расланды |
| гуманитар  фәннәр | УТЭ дир. урынбасары | Боерык №100-Б 28.08.2017ел. |
| МБ утырышында. | ______Л.Т.Хамитова | мәктәп директоры |
| Беркетмә №1 23.08.2017ел. | 28.08.2017ел. | ______А.Х.Хусаинов |
| Житәкче____Ф.Б.Вафина | | |

.

Гуманитар фәннәр циклы
методик берләшмәсенең
2017-2018 нче уку елына эш планы.

Төзеде методик берләшмә җитәкчесе
Вафина Ферддания Борисовна.

2017 нче ел.

**РМБ проблемасы:** “Заманча технологияләргә нигезләнеп, укытуның сыйфатын күтәрү».
**Методик берләшмәнең проблемасы:** «Укыту-тәрбия процессында заманча технологияләр, ИКТ нигезендә конкурентлыкка ия шәхес тәрбияләүдә дәресләрнең дәрәҗәсен, сыйфатын үстерү».
**Максаты:**

- татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты, тарих, җәмгыять белеме, музыка, инглиз теле дәресләренең нәтиҗәлелеген үстерү;
- фән укытучыларының методик осталыкларын үстерү һәм дәрес бирү ысулларын камилләштерү;
- укыту процессын заманча технологияләр, ИКТ нигезендә тәрбияви чаралар белән тыгыз бәйләнештә алып бару.

**Бурычлары:**
- укуның сыйфатын күтәрү;
- укытуның сыйфатын күтәрү;
-тәрбия процессын камилләштерү;
- укучыларны ГИА(ОГЭ) һәмБДИга ныклап әзерләү;
- заманча технологияләрне ныклап үзләштерү;
- фәннәр буенча яңа стандартларны (ФГОС ООО), программаларын өйрәнү .

**Тәрбия проблемасы**: «Конкурентлыкка ия, сәләтле һәм сәламәт укучы шәхесен тәрбияләүдә мәктәп һәм гаиләнең бердәм эшчәнлеге».(«Взаимодействие школы и семьи в воспитании здоровых, конкурентоспособных, развитых личностей.»)
Бүгенге җәмгыять укытучылар алдына замана таләпләренә җавап бирерлек, үз чиратында тормышта лаеклы урынын табарлык, туган телен, мәдәниятен,үз халкының кыйммәтләрен хөрмәт иткән, шулар белән горурланган һәм шул ук вакытта башка милләт вәкилләре белән җиңел аралашучы, коммуникатив, киң фикер йөртүче, максатчан шәхес тәрбияләү .
Замана җитди адымнар, кыю карарлар кабул итүне сорый. Иң беренче чиратта, бу-уку-укыту сыйфатын күтәрү,укучыларыбыз белеменең эзлекле һәм конкурентлыкка сәләтле булуы. Бүген балага белеем бирү генә җитми, ә бәлки аңа булачак һөнәрен сайлау һәм тормышта үзурынын табуда ярдәм итү зарур. Уку процессының мавыктыргыч һәм нәтиҗәле булуы өчен һәр укытучы җаваплы . Берләшмә утырышларының төпмаксаты-гуманитар фәннәрдән белемнең сыйфатын күтәрү, укытучыга методик яктан ярдәм итү, яңа технологияләрне өйрәнү, 5-7 нче сыйныфларда ФГОС программаларын өйрәнү, дәрес планнарын ,техник карталарны төзү,мониторинг алып бару,шулай ук”Дорожная карта по формированию необходимой системы условий реализации основной образовательной программы”ны эштә куллану.Фәннәр буенча эш программалары һәм календарь тематик планнар укытучылар тарафыннан төзелә,берләшмә утырышында тикшерелә һәмраслана. Эш программалары, календарь -тематик планнар Дәүләт программаларына, Стандартларына нигезләнеп, укуның сыйфатын тәэмин итәрлек итеп төзелә, контроль эшләр, тестлар саны төгәл билгеләнә, диктант, изложение һәм сочинение темалары, текстлары җентекләп сайлана.
Берләшмә утырышларында даими рәвештә норматив документлар өйрәнелә, кереш, административ, арадаш контроль эш биремнәре, мәктәп планы нигезендә узачак олимпиада биремнәре раслана. Мәктәп олимпиадасы биремнәре елдан –ел катлаулана, республика олимпиадаларына тәңгәлләштерелә. Биремнәр МКУ дан килә. Мәктәп һәм район,республика бәйгеләренә хәзерлек һәм андакатнашу белемнең сыйфатын үстерүгә ярдәм итә, чөнки бөтен фәннәр буенча материаллар кабатлана һәм системага салына. Бигърәктә, 9 нчыһәм 11нче сыйныф укучыларының белемнәрен тикшерү һәр фәниясенең төп бурычы. Уку елы дәвамында берничә тапкыр рус, теленнән,җәмгыять белеменнән 11 сыйныфта БДИ га әзерлек, 9 сыйныфта рус һәм татар телләреннән, инглиз, тарих,

җәмгыять белеменнән ГИА(ОГЭ) га әзерлекнең торышы тикшерелә. Башка мәктәпләргә барып имтихан биреп карау һәм Онлайн тестлары эшләү, укучыларга алдагы укуга зур этәргеч бирә.Укытучылар тарафыннан мониторинглар төзелә.
Гуманитар фәннәр циклына кергән укытучылар белән һәрдаим түгәрәк өстәл артында, укучыларны һәм укытучыларны борчыган мәсьәләләр хакында сөйләшү уздырыла. Аннан чыгу юллары бергәләп хәл ителә. Мәктәп, район, республика һәм Россия күләмендә уздырыла торган төрле чаралада педагоглар һәм укучылар актив катнашалар,үзләренең эшнәтиҗәләре белән уртаклашалар.
Уку елы дәвамында атналыклар, декадалар уздырыла. Бу чараларга "көчле" укучылар гына түгел, укулары “түбән”нәр да җәлеп ителә.
Фән укытучылары методик осталыкларын үстерү һәм дәрес бирү ысулларын камилләштерү өстендә дә эшалып баралар. Курсларга барып укып кайтулар, аттестация узу - эш нәтиҗәсенә уңай йогынты ясамый калмый. 2017-2018 нче уку елында татар теле һәм әдәбияты укытучысы Шарапова И.Д. сентябрь аенда КФУ да курслар узачак.

**Гуманитар циклның составы:**

| **Укытучының фамилиясе, исеме, этисенең исеме** | **Нинди уку йортын тәмамлаган, елы, белеме, вазифасы** | **Пед.стаж** | **Яше** | **Курслары** | **Аттестациясе** | **Категориясе** | **Проблемасы** | **Технологиясе** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **Хамитова Ландыш Талгатовна** | КГУ-1993ел татар теле һәм әдәбияты, музыка укытучысы; белеме - югары | 24 | 46 | 2015 ел КФУ; | 2015 ел | югары | «Татар теле һәм әдәбияты, музыка дәресләрендә, яңа технологияләр кулланып, укучылар белән индивидуаль эшләү» | “Технология развивающегося обучения” |
| **Хуснутдинова Лилия Ильфаровна** | ТГГИ-2004 ел, инглиз теле укытучысы, белеме-югары | 14 | 35 | 2015ел ГАОУ ДПО ИРО РТ | 2013ел | 1 | «Практик юнәлеш һәм яңа технологияләр кулану нигезендә инглиз телен укытуның сыйфатын күтәрү» | Уен технологиясе (Б.П.Никитин), чит тел укытуда коммуникатив укыту технологиясе |
| **Шәрәпова Илсояр Давлятовна** | КГПИ-1985ел,татар теле һәм | 32 | 55 | 2014ел | 2014ел | югары | «Халык педагогикасы һәм милли-төбәк | Традицион, А.Яхинның әдәбият укыту |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты укытучысы; белеме-югары | | | | | | компонентлары нигезендә, яңа технологияләр кулланып, укучы шәхесен үстерү» | технологиясе; шәхескә юнәлтелгән укыту технологиясе; индивидуаль укыту технологиясе; А.З.Рәхимовның үстерелешле укыту технологиясе; Е.Н.Ильинның әдәбият укыту технологиясе. |
| **Вафина Фердания Борисовна** | КГПИ-1990 ел; татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты укытучысы; белеме-югары | 27 | 50 | 2016ел<br><br>КФУ | 2012ел | 1 | « Рус теле һәм әдәбияты дәресләрендә,яңа технологияләр кулланып, укучылар белән индивидуаль эшләү» | Индивидуаль укыту технологиясе, компьютер технологиясе |
| **Гарифуллин Радик Абдуллович** | КГПУ-1997,тарих, җәмгыять белеме укытучысы; белеме-югары | 28 | 48 | 2014ел<br><br>КФУ | 2014ел | 1 | «Шәхескә юнәлтелгән тәрбия нәтиҗәсендә тирә -юнь шартларына социаль ярашу» | Мәҗ-Бүри нәтиҗәләр нигезендә дифференциаль тигезләп укыту |

**Телефон номерлары:**

1) Вафина Фердания Борисовна. Тел.89297236991
2) Хамитова Ландыш Талгатовна. Тел.8-8270353141
3)Шарапова Илсояр Давлятовна. Тел.89274207005
4)Хуснутдинова Лилия Ильфаровна. Тел.89377710084
5) Гарифуллин Радик Абдуллович. Тел.89600377490

**Методик циклның утырышлары.**

**1нче утырыш: 23 август**

1. 2017-2018 нче уку елына гуманитар циклның эш планын тикшерү һәм раслау.
2. Татар теле һәм татар әдәбиятыннан, рус теле һәм рус әдәбиятыннан, тарихтан, җәмгыять белеменнән, музыкадан,инглиз теленнән эш программаларын тикшерүһәмрасларгатәкъдим итү.
3. Татар теле һәм татар әдәбиятыннан, рус теле һәм рус әдәбиятыннан, тарихтан, җәмгыять белеменнән, музыкадан, инглиз теленнән календарь-тематик планнарны тикшерү һәм расларга тәкъдим итү.
4.2017- 2018 нче уку елында гуманитар фәннәр буенча кулланылачак дәреслекләрне барлау.
5.МБ нең положениесе, укытучыларның эш вазыйфасы инструкциясе, кабинет инструктажлары белән танышу.
6. Рус,татар телләре буенча кереш контроль эшләрнең материалларын карау Һәм раслау.
7.Өстәмә сәгать бирү планын карау һәм раслау (Дополнительный час по родному языку) һәм тикшерү

**2 нче утырыш: сентябрь**

1. Сентябрь аенда үткәрелгән кереш контроль эшләренең нәтиҗәсе белән танышу, анализын тикшерү.
2. КИМ гыүзгәрешләр белән танышу, пробный эшләр үткәреп карау, мониторингын төзү.
3. Беренче мәктәп тур олимпиадаларын үткәрү **.**
4. Төрлеләр**.**

**3 нче утырыш: ноябрь**

1.Мәктәп олимпиадасында җиңгән укучыларны район бәйгесенэ (муниципаль турга) әзерләү.
2.11 нче сыйныфта рус әдәбиятыннан йомгак иншасының (итоговое сочинение) үткәрү положениясе белән танышу,эшләү планын төзү.
3.«Русский медвежонок – языкознание для всех» Халыкара конкурсында катнашу.
4.Декабрь аенда үткәреләчәк административ контроль эшләрнең материалларын карау, раслау.
5.Төрлеләр.

**4 нче утырыш: январь**

1. Авыр укучылар белән эшнең торышын тикшерү.
2. Декабрь аенда үткәрелгән административ контроль эшләренең нәтиҗәсе белән танышу, анализын тикшерү.
3.Олимпиада нәтиҗәләре белән танышу.(2нче тур)
4.Тарих,җәмгыять белеме декадасын үткәрү программасын карау һәм раслау.
5.Инглиз теле декадасын үткәрү прогаммасы белән танышу һәм раслау.
6.Төрлеләр.

**5 нче утырыш: март**

1.Рус теле декадасын үткәрү прогаммасы белән танышу һәм раслау.
2.Татар теле һәм әдәбияты, музыка һәм рәсем сәнгате айлыгын үткәрү прогаммасы белән танышу һәм раслау.
3.Еллык контроль эшләрнең биремнәрен тәкъдим итү һәм раслау.(арадаш аттестация эшләре)

**6 нчы утырыш: май**

1.Еллык контроль эщләренә анализ ясау. (арадаш аттестация эшләре)
2.Һәр укытучының проблемасы буенча отчёты.
3.Секция эшенә нәтиҗә ясау.
4. Төрлеләр.